# ЯРАТАМ БИГРӘК МИН, ДУСЛАР

*сүзләре һәм көе – Шамил Сагаутдинов*

1. Яратам бигрәк мин, дуслар,
Матур язгы көннәрне,
Алкалы ак каеннарны,
Мәһабәт имәннәрне,

Һавадагы йолдызларның
Җемелдәп уйнаганын,
Урмандагы чишмәләрнең,
Урмандагы чишмәләрнең
Чылтырап сайраганын! } 2 тапкыр

2. Яратам бигрәк мин, дуслар,
Безнең дәртле җырларны:
«Минзәлә» белән «Эрбетне»,
«Арча» белән «Сарманны».

Тормышның авыр чакларын
Җиңел була кичәргә,
Читкә куеп кайгыларың,
Читкә куеп кайгыларың
Җырласаң бу көйләргә! } 2 тапкыр

3. Яратам бигрәк мин, дуслар,
Дус булып яшәгәнне,
Бүтәннәрнең хаталарын
Кичерә белгәннәрне.

Ачу ятмаса күңелдә,
Шәфкатьле булса йөрәк,
Матуррак үтәр гомерләр,
Матуррак үтәр гомерләр,
Дөнья булыр ямьлерәк! } 2 тапкыр

**Песня о том, что я люблю**

*Очень я люблю, ребята,
Наши степи, горы кряду,
Наши сказки, наши песни,
Наши танцы до упаду.*

*И еще люблю я тех, кто
Зла в душе таить не смеет,
Кто добро творит охотно
И других прощать умеет.*